**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**
**К А Р А Р**

**28.12.2023 ел** **№ 120**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 24 февралендәге 175 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2023 елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында», Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советының 24.02.2014 № 175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 9 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;
2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«20.Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының 24.02.2014г № 175 карары белән расланган Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**Совет рәисе урынбасары** **С.К. Маклаков**